**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

**егерме сигезенче утырыш**

**7 май 2024 ел** **№124** **Теләче ав.**

**Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 июнь 194 номерлы «Теләче авыл җирлеге муниципаль милкендә булган, аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм куллану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 июнь 194 номерлы «Теләче авыл җирлеге муниципаль милкендә булган, аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм куллану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (28.12.2018 №123 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Теләче авыл җирлеге муниципаль милкендә булган, аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм куллану тәртибе турында нигезләмәнең 6.1 пунктындагы «, адреслы инвестицион программалар белән» сүзләрен «һәм (яисә) региональ инвестиция программалары белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә халыкка җиткерергә.

Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Хаҗипов